*Мәктәп туры*

РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ
ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН
**ТАТАР ӘДӘБИЯТЫННАН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
(2025-2026 нчы уку елы)
**11 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты – 150 минут**
**Максималь балл – 40**

**1. Әсәрдә автор позициясе турында исегезгә төшерегез. Аның үзенчәлекләрен барлап языгыз. (5 балл)**

**Җавап:** ____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

**2. Рәсемгә игътибар итегез. Ул кайсы әсәр буенча ясалган? Әсәрнең исемен, авторын языгыз, әсәр геройларын атагыз. (5 балл)**



**Җавап**: ___________________________________________________________

_____________________________________________________________________

_____________________________________________________________________

**3. Болгар чоры әдәбияты кайсы чорны үз эченә ала? Дөрес җавапны билгеләгез. (1 балл)**

а) V – XII гасырлар

ә) IX – XIII гасырның беренче яртысы

б) XIII гасыр уртасы – XV гасырлар гасыр уртасы

**Җавап:** _________________________________________

**4. XX йөз башы чоры шагыйрен билгеләгез. (1 балл)**

а) Габдерәхим Утыз Имәни

ә) Сәгыйть Рәмиев

б) Равил Фәйзуллин

**Җавап:** _____________________________________


**5. Әсәрләрнең авторын, жанрын язгыз. (6 балл)**

а) «И күңел...» _____________________ ___________________

ә) «Яшь йөрәкләр» ______________________ __________________

б) «Мәхәббәт тәүбәсе» ______________________ ___________________

**6. а) Портретка игътибар итегез. Биредә кем сурәтләнгән? (1 балл)**



**Җавап**: ________________________________________

**б) Бу әдип турында өч фактны искә төшереп языгыз. (6 балл)**

**Җавап:**

1) ____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

2) ____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

3) ____________________________________________________________

____________________________________________________________

____________________________________________________________

**7. Шигырьне укыгыз, анда бирелгән хис-кичерешләрне, аларның сәбпләрен билгеләгез. (5 балл)**

**Бердәнбер**

Туган ил — бердәнбер.
Әниең — бердәнбер.
Әтиең — бердәнбер.
Син үзең — бердәнбер.

Калырсың беркөнне
дөнья каршында
бергә-бер!
Хәвефләр алдында —
бергә-бер.

Сынаулар алдында —
бергә-бер.
Бурычлар алдында —

бергә-бер.
Намусың алдында —
бергә-бер...

Башкарган эшеңә
ни дияр —
Ватаның,
әтиең,
әниең?

Аларның хөкеме —
иң гадел, бердәнбер!

Әтиең, әниең
куанып туялмас,
Әйтсәләр:
«Ул егет — Илдә бер!
Илдә бер!»

*Равил Фәйзуллин*

**Җавап:** ______________________________________________________________
______________________________________________________________________
______________________________________________________________________

**8. Кеше – иң зур кыйммәт, диләр. Сез килешәсезме? Әлеге фикерне дәвам итеп языгыз, әдәбияттан мисаллар китерергә дә онытмагыз. (10 балл)**